ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.21А, д.Малые
Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 21А йорт, Кече
Урыссу авылы., 423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» ноябрь 2025 ел № 3

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге составына керүче Биектау торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26, 92 маддәләре нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 19 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Биектау бистәсе, Тынычлык урамы, 26 йорт адресы буенча урнашкан бина янында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Биектау торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Биектау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 700 (җиде йөз) сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүдән үзара салым кертүгә ризамы?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Биектау торак пунктында Тынычлык урамы буенча юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (вак таш сатып алу һәм салу, ПГС, транспорт хезмәтләре күрсәтү, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

-урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Биектау торак пунктында энергияне саклый торган лампалар сатып алу, урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетына Биектау торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Н.С.Рәфыйков